| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**<br>**ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО**<br>**ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО**<br>**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **Татарстан Республикасы**<br>**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ**<br>**РАЙОНЫ ЛӘКЕ**<br>**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**<br>**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**Постановление** **Карар**

2026 ел, 30 нчы январь № 1

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә
җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә
күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында.

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "җирләү һәм җирләү эше турында" 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, "2026 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 23.01.2026 елдагы 30 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1.2026 елның 1 февраленнән Сарман муниципаль районының «Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен кушымталар нигезендә 9 678,63 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында»2025 елның 29 гыйнварындагы 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб адрес буенча һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://sarmanovo.tatarstan.ru/. веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Ю.Г.Антонов

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2026 елның 30 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 01.02.2026 елдан җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлегенә ир яисә хатынны, якын туганнарны, башка туганнарны, үлгән кешене күмүне үз өстенә алган законлы вәкилне яисә башка кешене күму мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт күрсәтү бәясе.

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4170,37 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1913,26 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 595,00 |
| Барлыгы | **9678,63** |

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесенең 2026 елның 30 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 01.02.2026 елдан ире, якын туганнары, башка туганнары яки үлгән кешенең законлы вәкиле булмаганда яки аларны күмү мөмкинлеге булмаганда, шулай ук җирләү бурычын үз өстенә алган башка затлар булмаганда, өйдә, урамда яки аның эчке эшләр органнары билгеләгәннән соң башка урында җирләү, күмү бурычын үз өстенә алган башка затлар булмаганда җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе.

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе-(сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Кәфенләү | 1 500,00 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 670,37 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1 913,26 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 595,00 |
| Барлыгы | 9 678,63 |